*...ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!*

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 2 2017. декабрь
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

*БУ АЙДА... предмет олимпиадаларының муниципаль туры тәмамланды. Мәктәбебездә инглиз теле, татар теле һәм география фәненнән уңышлы чыгыш ясаучылар бар.Район туры җиңүчеләренә алда тагы авыр сынаулар аша узасы. Барысына да уңышлар телибез!*

*БУ АЙДА... 7 нче декабрьдә 11 нче сыйныф егетләре рус әдәбиятыннан сочинение яздылар, үзенчә имтихан тапшырдылар. Имтихан тапшыру пункты үзебезнең Лашман урта мәктәбендә булуы аерым игътибарга лаек. Гомумән, Бердәм Дәүләт имтиханнары үткән уку елыннан барысы да безнең мәктәптә уздырылачагы турында әйтелде. Шәпме? Белмим. Әмма шунысы билгеле: өйдә стеналар да булыша.*

*БУ АЙДА... рәхәтләнеп Яңа ел бәйрәменә әзерләндек. Сыйныф бүлмәләрен бизәү, тәрәзәләргә рәсем төшерү, стена газетасын әзерләү, Яңа ел тамашасына сценарий оештыру, концерт номерлары хәзерләү – болар барысы да бик күңелле һәм мавыктыргыч иде. Хәерле имин еллар килсен, күңелләрдә дәрт кимемәсен!*

## ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН, ДУСЛАР!!!

***Күңелемнән теләк телим –***
***Булсын бары тынычлык.***
***Кар бөртеге кулда эри –***
***Яңа елга юл ачык.***
***Бүләк белән тулган капчык,***
***Елмаюлар, котлаулар.***
***Кемдер сәлам җибәрәме?***
***Чәчкә куна ак карлар.***
***Актан киенгән урманнар,***
***Йомшак шәл иңнәрендә.***
***Бәхет китер син, Яңа ел,***
***Илемә, көннәремә.***



**БҮЛӘК АЛУ НИЧЕКМЕ? БҮЛӘК АЛУ - БИК РӘХӘТ!**
**ШУЛ БҮЛӘКНЕ БИРҮЧЕГӘ**
**БИК ТӘ, БИК ТӘ ЗУР РӘХМӘТ!!!**



***2016 нчы елның соңгы көннәре күңелле сюрпризларга бик бай булды. Соңгы уку көнендә юмарт Кыш бабай үзенең мөлаем Кар кызы белән һәр сыйныфка кереп барлык укучыларны да да Яңа ел белән котлады. Әле алай гына да түгел, һәр укучыга тәмлүшкәләр белән тулы Яңа ел пакеты өләште! Бу күңелле сюрпризны оештыручы авылдашыбыз, бүгенге көндә Казанда эшләүче МИНСӘГЫЙТЬ ЗАКИР улы ШАКИРОВКА зур рәхмәтебезне җиткерәбез, исәлек-саулык телибез. Балаларның куанычы сезгә зур уңышлар булып әйләнеп кайтсын.***

# “МИНЕМ БУШ ВАКЫТЫМ – МИНЕМ СӘЛАМӘТЛЕГЕМ!”



Күптән түгел Балык Бистәсендә Татарстан Республикасы беренчелегенә уктан ату буенча ярышлар булып узды. Анда безнең биш кешедән торган мәктәп командасы да катнашты. Рәсим Вафин һәм Ләйсән Миһманова үз категорияләрендә икенче урынга чыкканнар.



“Микст” күнегүдә дә (бер егет + бер кыз) алар сынатмаганнар, спорт мастерларыннан гына калышканнар һәм көмеш медальләр белән бүләкләнгәннәр. Калган укучылар да сынатмаган, Гатина Фәйрүзә ату буенча III Үсмерләр разряды таләбен үтәсә, Камалова Зөлфия 8 нче, Газимзянова Гөлинә 10 нчы урынны яулады. Балык Бистәсендә узган әлеге ярышларда Россиянең алты төбәгеннән 14 команда, 115 спортчы көч сынашкан. “Ату белән шөгыльләнү бик кызык”,-ди безнең 10 нчы сыйныф егетләре, кызлары. Яңа ел аларга да уңышлар алып килсен, шулай ук аларның тренерлары Фаиз Тәүфикъ улына да яңа үрләр насыйп булсын.

## *ШИГЪРИ ПОЧМАК*

***Рәнҗетмик кошкайларны!***

*Кыш җиттеме – кошлар өчен,*
*Без ашханә ачабыз,*
*Җимлекләр ясап эләбез,*
*Кошларны ашатабыз.*
*Кошларга таш атмагыз!*
*Баласын елатмагыз!*
*Алар безнең дусларыбыз,*
*Берүк кыерсытмагыз.*
*Буранлы салкын кышларда*
*Ярдәм итик кошларга.*
*Җимлекләргә азык салсак,*
*Җиңел булыр кышларга.*



**Яратам әбиемне**

Яратам әбиемне,
Сөйли ул көлә-көлә.
Укыганын да күрмим,
Миннән күбрәк белә.
Аңламаганым аңлата
Татлы тел белән генә.
“Яхшы йөр, кеше бул,
Иреш,- ди,- теләгенә!”

***Әбием.***

***Минем әби бик әйбәт,***
***Гел көлеп кенә тора.***
***Балакаем дип әйтеп,***
***Сөеп, иркәләп тора.***
***Әбием һәркөн безгә***
***Тәмле ашлар пешерә.***
***Назлы сүзләре белән***
***Күңелемне күтәрә.***
***Әбиемне бик яратам,***
***Ул да мине ярата.***
***Минем әбидән дә әйбәт***
***Кеше юктыр дөньяда.***

*Бу матур кызны танойсызмы? Бу 5 нче сыйныф укучысы Диләрә Гатина. Уку алдынгысы, бик матур итеп җырлый, гомумән мәктәбебезнең иң булган кызларыннан. Ул әле тагын иҗат эше белән дә шөгыльләнә икән. Аның шигырьләрен, хөрмәтле укучыларыбыз, сезгә дә тәкъдим итәбез.*



***Диләрәгә иҗади уңышлар теләп калабыз.***